КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 299

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 27 апрель, 211 нче; 2006 ел, 15 июнь, 303 нче; 2006 ел, 17 июль, 366 нчы; 2008 ел, 25 июль, 536 нчы; 2009 ел, 30 март, 192 нче; 2009 ел, 25 май, 333 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 879 нчы; 2011 ел, 23 май, 404 нче; 2011 ел, 21 декабрь, 1027 нче; 2012 ел, 6 февраль, 86 нчы; 2012 ел, 17 июль, 605 нче; 2012 ел, 20 декабрь, 1110 нчы; 2013 ел, 31 май, 367 нче; 2017 ел, 14 гыйнвар, 7 нче; 2017 ел, 13 сентябрь, 668 нче; 2019 ел, 17 декабрь, 1159 нчы; 2022 ел, 27 декабрь, 1427 нче; 2023 ел, 25 февраль, 184 нче; 2023 ел, 25 март, 350 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы «Инвестицияләр күләме кимендә 15 млрд.сум карала торган масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Җир кодексының $39^3$ статьясы нигезендә бирелгән, ясалма булдырылган җир кишәрлекләрендә һәм алар белән чикләре чиктәш булган җир кишәрлекләрендә

объектлар урнаштыру өчен (төзелеш чорын кертеп, биш ел срок белән)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | |
|---|---|
| «Инвестицияләр күләме кимендә 15 млрд.сум карала торган масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясы нигезендә бирелгән, ясалма булдырылган җир кишәрлекләрендә һәм аларга якын урнашкан җир кишәрлекләрендә объектлар урнаштыру өчен (төзелеш чорын кертеп, биш ел срок белән) | 1». |

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин